**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Киекле авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ**

«04» ноябрь 2022 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Киекле авыл җирлеге Киекле авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

Киекле авыл җирлегенең Киекле авылы территориясендә теркәлгән һәм яшәүче, 1 гр инвалидлардан, балачактан инвалид булганнарның, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларның тол калган хатыннарыннан кала, балигъ булган һәр кешедән 2023 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Халыкны эчә торган су белән тәэмин итү максатыннан суүткәргеч челтәрләрне ремонтлау өчен кирәкле товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу, суүткәргеч челтәрләрне реконструкцияләү, яңа суүткәргеч челтәрләр үткәрү буенча төзелеш-монтаж эшләрен башкару өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу;
- Киекле авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту, таш, кирпеч, грунт, вак таш, ком, асфальт (сатып алу, ташу, салу), чокырларны ямау (сыек асфальт);
- Киекле авылында урамнарны яктыртуны оештыру өчен эшләр һәм хезмәтләр, товарлар сатып алу;

авыл җирлегенең торак пунктларындагы урамнарны, территорияләрне, Киекле авылындагы өч зиратны төзекләндерү һәм сезонлы карап тоту (коймаларны ремонтлау, агачларны кисү, үләнне чабу, коймаларны буяу);

- Киекле авылында спорт-массакүләм һәм мәдәни-массакүләм чараларны оештыру һәм уздыру өчен товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алу;
- Киекле авылы территориясен төзекләндерү һәм карап тоту өчен товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алу;
- Киекле авылында халыкның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алу.

Халык җыенында рәислек итүче: Л.И. Кашапова

Киекле авыл җирлеге башлыгы: Л.И. Кашапова